**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМАШИРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ямаширмэ авылы, Совет ур., 5

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422735,Республика Татарстан,Высокогорский район, с. Ямашурма, ул.Советская,5

тел./факс 8(84365) 777-02, e-mai-Yamash Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**25 март 2019 ел** **№95**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октяберендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, нигезендә, Биектау прокуратурасының 2019 елның 24 гыйнварындагы 02-08-03-2019 номерлы тәкъдиме нигезендә, Ямаширмэ авыл җирлеге муниципаль программаларын камилләштерү һәм нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан, Биектау муниципаль районы “Ямаширмэ авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Ямаширмэ авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм башкарма комитетның мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ямаширмэ авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Ф.К.Мухтаров

Кушымта
РАСЛАНГАН
ТР Биектау муниципаль районы
Ямаширмэ авыл җирлеге
Башкарма комитеты карары
белән
25 март 2019 ел № 95

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге, муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү Тәртибе (алга таба – Тәртип), Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октяберендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләп чыгарылган.

1.2. Муниципаль программа астында әлеге Тәртиптә Татарстан Республикасы Биектау мунципаль районы Ямаширмэ башкарма комитеты катнашында җирле бюджет хисабына гамәлгә ашырыла торган программа күз алдында тотыла (алга таба – муниципаль программа). Муниципаль программалар максатлар, ресурслар һәм үтәлү вакытын үз эченә ала, җитештерү, социаль-икътисади, оештыру-хуҗалык һәм башка чаралар белән тыгыз бәйле, Татартсан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлегенең (алга таба – Җирлек) муниципаль, икътисади, экологик, социаль-мәдәни үсешен нәтиҗәле хәл итүгә юнәлтелә;

1.3. Муниципаль программа үз кысаларындагы төгәл бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән берничә ярдәмчел программаны үз эченә алырга мөмкин. Муниципаль программаның ярдәмчел программаларга бүленүе, хәл ителәсе мәсьәләләрнең катлаулыгыннан һәм масштабыннан, чишү юлларын нәтиҗәле оештыру кирәклегеннән чыгып, гамәлгә ашырыла.

1.4. Методик яктан җитәкчелек итү, эшкәртүне координацияләү, һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыру әлеге Тәртипкә нигезләнеп башкарыла.

1.5. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру вакыты проблема, көтелгән нәтиҗә һәм ресурс мөмкинлекләренә карап билгеләнә.

Муниципаль программалар үтәлү вакыты буенча түбәндәгеләргә буленә:

- кыска вакытлы (1-2 елга)
- уртача вакытлы (3-5 елга)
- озак вакытлы (6-10 елга һәм аннан күбрәк).

Муниципаль программаларны эшләү һәм раслау шушы Тәртипнең 1 нче кушымтасына нигезләнеп эшләнә һәм үз эченә түбәндәге төп этапларны ала:

- муниципаль программаны эшләү;

- муниципаль программаның проектын килештерү;

- муниципаль программаның проектына экспертиза үткәрү, шулай ук бәйсез экспертлар белән дә (кирәк булганда);

- муниципаль программаны раслау.

## 2. Муниципаль программаны формалаштыру

2.1. Муниципаль программа түбәндәге бүлекләрдән тора:

- әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасына нигезләгән муниципаль программаның паспорты;

- мунинципаль программа чишүгә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасы;

- муниципаль программаның вакытларын һәм этапларын үз эченә алган төп максатлар һәм бурычлар, ярдәмчел программаның, программа чараларының һәм аларның бурычлары киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларының кыскача исемлеге һәм тасвирламасы;

- муниципаль программаның ресурслар белән тәэмин ителеше нигезләре;

- үз эченә программа белән идарә итү механизмын да кертеп, муниципаль программаны гамәлгә ашыру механизмы;

- муниципаль программаның икътисади, социаль, экологик нәтиҗәлелеген бәяләү;

- муниципаль программаның бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү.

2.2. Муниципаль программаның эчтәлегенә карата түбәндәгеләр таләп ителә:

Муниципаль программаның беренче бүлеге проблемалар исемлеге, аларны нигезләү, һәм, шул исәптән, аларның ни сәбәпләр аркасында барлыкка килүе, шул сәбәпләрне нигезләүдән торырга тиеш.

Муниципаль программаның икенче бүлеге максатларның җәелдерелгән формулировкасыннан һәм программаның бурычларыннан, ярдәмчел программалар исемлегеннән һәм чаралардан, бурычларны хәл итүне тормышка ашыру тәкъдимнәреннән һәм куелган максатларга ирешүне таләп итүдән, һәр чараны тормышка ашыру өчен кирәкле мәгълүматьләрне (финанс чыганакларга нигезләп) һәм үтәлү вакытын күрсәтеп, программаның нәтиҗәсен бәяләү индикаторын ачыклаудан торырга тиеш.

Программаның максатларына таләпләр:

- спецификациялелек (максатлар муниципаль программаның муниципаль заказчылары компетенциясенә туры килергә тиеш);

- үтәлешлек (максатлар башкарып чыгарлык булырга тиеш);

- үлчәмлелек (нәтиҗәләрне бәяләп булырга тиеш);

- куелган сроклар белән тәңгәллек (муниципаль программада аерым максатларның үтәлү вакыты һәм этаплары курсәтелгән булырга тиеш).

Бүлектә программа формалаштырган максатларны үтәү өчен куелган бурычларны нигезләү, максатларның үтәлеш вакыты, программа үтәлешенең төп этапларын гамәлгә ашыру, һәр этапның планлаштырылган фараз индикаторы күрсәткечләре һәм һәр этапның бурычлары, шулай ук, муниципаль программаның вакытыннан алда үтәлешен үз эченә алу булырга тиеш.

Нәтиҗәләргә бәя бирү индикаторлары турында мәгълүматлар муниципаль программа максатлары, бурычлары, чаралары киселешендә әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасында күрсәтелә.

Муниципаль программаның өченче бүлегендә еллар буенча һәм финанслау чыганакларына бүленеп, ресурс белән тәэмин итүне нигезләү булырга тиеш.

Моннан тыш, бу бүлектә бюджеттан тыш акча җәлеп итү мөмкинлеге яки мөмкин булмавы һәм программа чараларын тормышка ашыруга муниципаль берәмлекләрнең бюджет акчаларын җәлеп итү мөмкинлеге һәм акчаны җәлеп итүнең төп механизмнары тасвирланырга тиеш. Муниципаль программаның дүртенче бүлегенә төп таләпләр шушы Тәртипнең 5 нче бүлегендә күрсәтелгән.

Муниципаль программаның бишенче бүлегендә программаны тормышка ашырганда килеп чыгарга мөмкин булган социаль, икътисади һәм экологик нәтиҗәләр, шулай ук муниципаль программаның бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү тасвирланырга тиеш.

2.3. Муниципаль программада катнашучылар муниципаль программаның алар тарафыннан тормышка ашырыла торган төп чараларга һәм ярдәмчел программаларга кагыла торган өлешенең проектына килешү төзиләр. Муниципаль программага ярдәмчел программаны керткәндә, ярдәмче программаның заказчысының вәкиле белән килештерү дә җитә (берничә заказчы вәкиле булганда, ярдәмче программа координаторы белән).

## 3. Муниципаль программага экспертиза һәм бәяләмә

3.1. Муниципаль программаның проектын бәяләүне Башкарма комитет, төп игътибарны түбәндәгеләргә юнәлтеп үзе башкара:

- программа чараларның нигезләнгән булуы, комплекслыгы һәм экологик куркынычсызлыгы, аларны тормышка ашыру сроклары;
- финанслау күләмнәренең нигезләнүе;
- муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен бюджеттан тыш акчалар җәлеп ителүе;
- муниципаль программаның үтәлеш механизмының нәтиҗәлелеге;
- муниципаль пограмманың тулаем алганда социаль–иктисади нәтиҗәлелеге, программаны тормышка ашырудан соң көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм җирлектәге халыкның тормыш сыйфаты күтәрелү бәяләмәсенә йогынтысы.

3.2. Җирлекнең Башкарма комитеты муниципаль программаларның проектларын бәяләгәннән соң, кирәк булса, алар шулай ук махсус (билгеле бер өлкәдә махсус белемнәр таләп иткән мәсьәләләрне өйрәнү) һәм бәйсез экспертиза узарга тиешләр.

Әлеге Тәртип буенча каралган экспертиза барышында муниципаль программаларның проектларының куела торган таләпләргә туры килүе билгеләнә, кирәк булган очракта, муниципаль программаларның проектларын эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр формалаша.

Муниципаль программа проекты каралганда һәм кабул иткәндә махсус һәм бәйсез экспертизаларның нәтиҗәләре исәпкә алына.

## 4. Муниципаль программаларны финанслау

4.1. Расланган муниципаль программалар җирле бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына тормышка ашырылалар.

4.2. Муниципаль программада федераль һәм республика бюджетыннан акчалар каралган булырга мөмкин.

4.3. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен махсус фондлар оештырыларга мөмкин. Әлеге фондларларга юллана торган акчаларның чыганаклары булып: оешма һәм предприятие карамагында калган табыш, җирлекнең бюджет һәм бюджеттан тыш акчалары һәм башкалар чыганаклар булырга мөмкин.

## 5. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыру буенча идарә һәм аның үтәлешен контрольдә тоту

5.1. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру буенча идарәнең ысуллары һәм формалары муниципаль заказчы белән билгеләнә.

Программада муниципаль заказчының-координаторның һәм муниципаль программаны башкаручыларның, программаны тормышка ашыру вакытлары һәм күләмнәре өлешендә, үзара бәйләнешлеге чагылырга тиеш.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру, гамәлдәге федераль законга таянып, муниципаль программаның заказчысы һәм программа чараларын гамәлгә ашыручы һәрбер башкаручы белән муниципаль ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен продукция алуга һәм тәэмин итүгә кабул ителгән муниципаль контрактлар (шартнамәләр) нигезендә башкарыла.

5.2. Муниципаль программаны башкаручы, бүленеп бирелә торган муниципаль программаның финанс чараларын исәпкә алып, чираттагы финанс елына ел саен максат индикаторларын, муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны, муниципаль программаны гамәлгә ашыру механизмнарын һәм аны башкаручылар составын ачыклый.

5.3. Муниципаль программага яңа ярдәмче программалар өстәү һәм аларны раслау муниципаль программаларны эшләп чыгару һәм гамәлгә ашыру билгеләгән тәртиптә башкарыла.

5.4. Муниципаль программаларны башкаручылар җирлек Башкарма комитетына программаларның эш барышын тормышка ашыру турында мәгълүматны һәм финанс чараларын кулануның нәтиҗәлелеген юнәлтәләр.

Еллык гомуми хисапка эшләнмәгән чаралар турында мәгълүмат та кертелергә тиеш.

5.5. Еллык хисап әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы билгеләгән форма буенча тутырылган статистик мәгълүматны һәм түбәндәге бүлекләрдән торган аналитик мәгълүматны үз эченә ала:

а) хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләр;

б) билгеләнгән вакытта башкарылган һәм башкарылмаган эшләр (сәбәпләрен күрсәтеп), чаралар исемлеге;

в) муниципаль программаны тормышка ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;

г) чараларны башкару өчен бюджет ассигнованияләре һәм башка чараларны файдалану турында мәгълүматлар;

д) муниципаль программага муниципаль заказчы керткән үзгәрешләр турында мәгълүмат.

Муниципаль программаларның план һәм хакыйкый нәтиҗә күрсәткечләре арасында әһәмиятле аерма булган очракта, аларга йогынты ясаган факторларга анализ ясала. Анализ вакытында муниципаль заказ бирүче тәэсир итә ала торган эчке факторлар һәм аңа бәйле булмаган тышкы факторлар аерылып күрсәтелә.

## 6. Муниципаль программаларның нәтиҗәлелеген бәяләү

6.1. Муниципаль программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү түбәндәгечә үткәрелә:

1) оценки степени достижения целей и решения задач муниципальной программы в целом путем сопоставления фактически достигнутых значений индикаторов муниципальной программы и их плановых значений, приведенных в таблице 1, по формуле: тулаем алганда муниципаль программаның бурычларын үтәү һәм максатларга ирешү дәрәҗәсен бәяләү, түбәндә күрсәтелгән 1 таблицадагы формула буенча, муниципаль программаның ирешелгән индикатор күрсәткечләрен пландагы күрсәткечләр белән чагыштырып башкарыла:

$$Сд = Зф / Зп * 100\% ,$$

монда:

Сд - максатларга ирешү (бурычларны чишү) дәрәҗәсен бәяләү;

Зф - дәүләт программасы индикаторының хакыйкый мәгънәсе (күрсәткече);

Зп - күтәлгән үсеш тенденциясе булып үсеш торган муниципаль программаның (индикаторлар (күрсәткечләр) өчен) пландагы индикаторы мәгънәсе (күрсәткече), яки

Сд =Зп /Зф *100% (көтелгән күрсәткечләр тенденциясе киму булган индикаторлар (күрсәткечләр) өчен);

2) планлаштырылган чыгымнарның дәрәҗәсе һәм җирле бюджет акчаларын һәм муниципаль программаның ресурслар белән тәэмин итүче башка чыганакларын нәтиҗәле файдалану дәрәҗәсе тәңгәллеге – муниципаль программаның тулаем һәм ярдәмче прораммаларның фактта һәм планда булган финанслау күләмнәренең, һәм ярдәмче прораммаларның тулаем (төрле дәрәҗәге бюджетлар, бюджеттан тыш чыганаклар) барлык ресурс белән тәэмин итүче чыганаклардан да фактта һәм планда булган финанслау күләмнәренең тәңгәллеген чагыштырып, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Уф =Фф /Фп *100% ,

биредә:

Уф - муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашыру буенча төп чараларны финанслау дәрәҗәсе;

Фф - муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашыру өчен юнәлдерелгән чараларның финанс ресурсларының факттагы күләме;

Фп - билгеле хисап чорында муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) тормышка ашыруга юнәлдерелгән финанс ресурсларының план күләме.

3) ярдәмче программаларның төп чараларын башкаруның турадан-туры нәтиҗәсе булган факттагы һәм еллык муниципаль программаны гамәлгә ашыру планнары нигезендә, план күрсәткечләрен елларга бүлеп чагыштыру нигезендә муниципаль программаларны гамәлгә ашыру чараларының дәрәҗәсе (турыдан-туры көтелгән күрсәткечләрне гамәлгә ашыру нәтиҗәләре) билгеләнә.

Муниципаль программалар гамәлгә ашырулучы чираттагы ел башына кадәр җаваплы башкаручы муниципаль программаның (ярдәмче программаларның) һәр күрсәткеченә (индикаторына) муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны чагылдырылган түбәндәге интерваллар күрсәткечләрен билгели:

югары нәтиҗәлелек дәрәҗәсе;
канәгатьләндерерлек нәтиҗәлелек дәрәҗәсе;
канәгатьләндерелмәслек нәтиҗәлелек дәрәҗәсе.

Муниципаль программада югары нәтиҗәлелек дәрәҗәсе тиешле елга интервалның түбән чиге планлаштырылган күрсәткечтән (индикатордан) пландагы үсешнең 95 процент күрсәткеченнән (индикатордан) башлап; муниципаль программаның канәгатьләндерерлек нәтиҗәлелек дәрәҗәсе тиешле елга

планлаштырылган күрсәткечтән интервалның түбән чиге тиешле пландагы үсешнең 75% күрсәткеченнән башлап билгеләнә. Муниципаль программаны тормышка ашыруда югары нәтиҗәлелек дәрәҗәсе буларак билгеләнә, әгәр дә:

муниципаль программаның һәм аның ярдәмче программаларының югары нәтиҗәлелек дәрәҗәсе планга туры килгән интервал зурлыгының 95% һәм аннан күбрәк күрсәткечләр билгеләсә;

муниципаль программаның төп чараларын (Уф) финанслауны гамәлгә ашыру дәрәҗәсе кимендә 95% тәшкил итсә, ярдәмче муниципаль программаларның төп чараларын (Уф) финанслау, гамәлгә ашыру дәрәҗәсе ким дигәндә 90% тәшкил итсә;

хисап елында планлаштырылган чараларның кимендә 95% тулы күләмдә үтәлсә.

Муниципаль программаны тормышка ашыруда канәгатьләндерерлек нәтиҗәлелек дәрәҗәсе буларак билгеләнә, әгәр дә:

муниципаль программаның һәм аның ярдәмче программаларының югары нәтиҗәлелек дәрәҗәсе планга туры килгән интервал зурлыгының 80% һәм аннан күбрәк күрсәткечләр билгеләсә;

муниципаль программаның төп чараларын (Уф) финанслауны гамәлгә ашыру дәрәҗәсе кимендә 70% тәшкил итсә;

хисап елында планлаштырылган чараларның кимендә 80% тулы күләмдә үтәлсә.

Әгәр муниципаль программаны гамәлгә ашыру югарыда китерелгән таләпләргә җавап бирмәсә, аны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелек дәрәҗәсе канәгатьләндерелмәслек дип бәяләнәчәк. Муниципаль программаларны тормышка ашыру барышы һәм нәтиҗәлелеген бәяләү турында җыелма еллык хисап Биектау муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырыла.

6.2. Муниципаль программаларны координацияләү уздыруны һәм мониторинг нәтиҗәләрен гамәлгә ашыруны алдан карауны җирлек башлыгы башкара.

6.3. Җирлек Башкарма комитетының күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча, элек расланган муниципаль программаны туктату яки чираттагы финанс елыннан башлап программаны үзгәртү турында, шул исәптән, муниципаль программаны финанслау өчен бюджет ассигнованияләренең күләмен үзгәртү кирәклеге турында, карар кабул итәлергә мөмкин.

6.4. Муниципаль программага аның параметрларына тәэсир итүче үзгәрешләр кертү җаваплы башкаручының инициативасы буенча, яисә җирлек башлыгы күрсәтмәләрен үтәү йөзеннән, шул исәптән, муниципаль программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре мониторингы күрсәткечләре буенча, әлеге Тәртип нигезендә башкарыла.

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә

Муниципаль программаны эшләү һәм раслауның
ЭТАПЛАРЫ ҺӘМ СРОКЛАРЫ

| Муниципаль программаны эшләү һәм раслау вакытлары | Муниципаль программаны эшләү һәм раслау этаплары |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлегенең чираттагы финанс елына бюджет кабул итү елыннан алдан килгән ел | Муниципаль программаның проектын әзерләү |
| | Муниципаль программаның проектын килештерү |
| | Муниципаль программаның концепция проектын экспертизалау, шул исәптән, бәйсез экспертлар белән |
| | Муниципаль программаны раслау |
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлегенең чираттагы финанс елына бюджет кабул итү елы | Муниципаль программаның проектын әзерләү |
| | Муниципаль программаның проектын килештерү |
| | Муниципаль программа проектын экспертизалау, шул исәптән, бәйсез экспертлар белән |
| | Муниципаль программаны раслау |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә
2 нче номерлы форма

Муниципальной программаның
ПАСПОРТЫ

| Күрсәткечнең исеме | Күрсәткечнең билгеләмәсе |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | |
| Муниципаль заказчы (муниципаль заказчы - координатор) | |
| Муниципаль программаның төп эшләүчеләре | |
| Муниципаль программаның максатлары һәм бурычлары | |
| Муниципаль программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | |
| Ярдәмчел программалар исемлеге | |
| Муниципаль программаны финанслауның елларга бүлеп күләмнәре һәм чыганаклары | |
| Муниципаль программаның көтелгән ахыргы нәтиҗәләрен тормышка ашыру максатлары (анын нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары) елларга бүленгән бюджет нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре | |

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә
3 нче номерлы форма

# Муниципаль программа нәтиҗәләренең МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ һәм программа чаралары буенча финанслау

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Ярдәмчел программаларның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның күрсәткечләре | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | База елы | 1 нче ел | 2 нче ел | n-нчы ел | 1 нче ел | 2 нче ел | n-нчы ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |

4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә

4 нче номерлы форма

| Күрсәткечнең исеме | Күрсәткечнең билгеләмәсе |
|---|---|
| Муниципаль программаның реквизитлары, гамәлгә ашыру чоры | |
| Исәп тотучы оешманың исеме | |
| Муниципаль программаны раслау турындагы норматив хокукый актның исеме | |
| Формаларны төзү өчен җаваплы вазыйфаи зат (Ф.И.О., вазыйфасы, элемтә өчен телефон) | |

____________ 20__ елга

муниципаль программаны тормышка ашыру турында

ХИСАП

| №№ т/б | Ярдәмче программаның исеме (чаралар, бүлекләр) | Финанслау чыганагы (барлыгы, шул исәптән, Россия Федерациясе бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет, бюджеттан тыш чыганаклар) | Программаны раслау турындагы норматив хокукый акт буенча, хисап елына план буенча финанслау күләме, мең сум | Программа буенча хисап чорына бирелгән (лимит), мең сум | Финанслау проценты | Ел башыннан фактта кулланылган чыгымнар (башкаручының счетыннан күчерелгән), мең сум | Үлчәү берәмлеге индикаторының исеме | Индикаторның күрсәткече | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | Узган ел | | Агымдагы ел | | Үтәлеш проценты | Киләсе елга план |
| | | | | | | | | план | факт | план | факт | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | |
| Программа | | Барлыгы | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| буенча барлыгы | Россия Федерациясе бюджеты | | | | | | | | | | | | |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | | | | | | | | |
| | бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | | | | | | | |